КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 февраль г.Казань № 68

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан тану турында» 2024 ел, 24 сентябрь, 823 нче карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан тану турында» 2024 ел, 24 сентябрь, 823 нче карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.5 пункт өстәргә:

«3.5. Сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертү әлеге Тәртипнең 3.4. пунктында каралган сайлап алуны уздыру турында игъланны формалаштыру тәртибенең шундый ук тәртибендә, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә 3 календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 5.7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

6.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

6.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 6.12 пункт өстәргә:

«6.12. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге Тәртипнең 6.10 пунктында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

7.1 пунктта:

дүртенче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин